КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 февраль г.Казань № 185

2023 елда Илһам Шакиров исемендәге
Республика премиясен бирү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясе турында» 2020 ел, 22 август, 723 нче карарын үтәү йөзеннән һәм Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен бирү комиссиясе утырышының 2023 елның 7 февралендәге ВШ-12-25 номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2023 елда Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен түбәндәге дүрт кешегә бирергә:
«Вокал (хатын-кызлар)» номинациясендә – Флюра Зиатдин кызы Асеевага (Сөләймановага);
«Вокал (ир-атлар)» номинациясендә – Фирдинант Абдулла улы Сәлаховка;
«Халык җыры» номинациясендә – Фәүдәт Әхмәтзыя улы Гыйләҗевка;
«Халык җыры» номинациясендә – Әсхәт Әсәдулла улы Хисмәтовка.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин